**Ф.Р. Сибгаева**
*Казан ш.*

# ТАТАР ТЕЛЕНДӘ «МӘХӘББӘТ» МӘГЪНӘСЕН БЕЛДЕРГӘН АНТРОПОНИМНАР

**Аннотация:** В разные исторические периоды отношение к такому чувству, как любовь имело свои особенности. В восприятии и понимании чувства *любви* в тюрко-татарской национальной картине мира присутствуют элементы западной, восточной, европейской философии и влияние тысячелетней исламской религии. Группа имен со значением любовь является одним из большой и распространенной среди арабо-персидских заимствований. Личные имена со значением любовь были распространены и до принятия ислама. После принятия ислама эта традиция нашла новое воплощение.

Татар исемнәре, татар халкының теле, тарихы, дине һәм мәдәниятенең аерылгысыз бер өлеше буларак, тарихи-лингвистик яссылыкта фәнни өйрәнү өчен гаять актуаль бер өлкә. Исемнәр антропонимиконыбызга хас булган тарихи-лингвистик үзенчәлекләрне, закончалыкларны, исемнәребезнең динамикасын, кулланылыш-үсеш эволюциясен эзлекле һәм системалы итеп тикшерергә антропонимик һәм лингвомәдәни чынбарлыкны тулырак чагылдырырга ярдәм итә.

Татар халкы элек-электән яңа туган сабыйга исем кушуга бик җитди караган. Баланың әти-әнисенә исемне туганнары, кардәш-тумачалары сайлашкан. Исеме җисеменә туры килә торган матур эчтәлекле, аһәңле, җиңел һәм анык әйтелешле исемнәр бирергә тырышкан, ә мондый исемнәр татар халкында бик күп. Без бу мәкаләдә исә мәхәббәт, сөю, ярату мәгънәсен белдергән антропонимик кырга киңрәк тукталып үтәрбез.

Татар халкында мәхәббәт синтез рәвешендә күзаллана, чөнки бу хистә төркиләргә, мөселманнарга, европалыларга, христианнарга хас булган үзенчәлекләр теге яки бу күләмдә тупланган. Татарлар өчен мәхәббәт, бер яктан, шәхесне каһарманлыкка, бөеклеккә, рухи үсүгә алып килергә сәләтле илаһи көч булса, икенчедән, ул һәр кеше башыннан уза торган тормышчан хис, җан һәм тән бердәмлегенең чагылышы. Ул гомер-гомергә татарлар өчен яшерен, серле булган, аны ят күзләрдән яшергәннәр, саклаганнар.

Татар хатын-кызы язма әдәбиятта, шигърияттә илаһилаштырыла, гүзәллек символына кадәр күтәрелә, сакраль статуска ия зат дип карала. Рус халкы тарихында хатын-кыз ир-атларны аздыручы, юлдан яздыручы итеп сурәтләнсә, татарларда исә кешелек дәверләр буе туплаган, буыннардан килгән тәҗрибәне, гореф-гадәтләрне, байлыкны танучы һәм аны икенче яртысы белән киләчәккә илтүче зат итеп сурәтләнә.

*Мәхәббәт* лексик берәмлеге үзенең этимологиясе белән гарәп теленә барып тоташа. Гарәп чыгышлы *мәхәббәт, мәхәббәтүн* сүзләре М.И. Мәхмүтов, К.З. Хәмзин, Г.Ш. Сәйфуллиннар төзегән «Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге»ндә татар теленә *сөю, сөешү, гыйшык,* ә рус теленә исә *любовь; привязанность* дип тәрҗемә ителә [Мәхмүтов, 1993: 339].

Тел гыйлемендә *«Мәхәббәт»* кырын белдерә торган *мәхәббәт* лексемасының яшәеш үзенчәлекләрен карап үтик: *мәхәббәт* – ярату, сөю (сөелү), сөю-сәгадәт, гыйшык, гашыйк булу (гыйшык-мыйшык), дәрт, дәрт-дәрман, назлау, иркәләү, ошату, якын итү; *ярат|у* – минем ~ кан кешем, эшем; ~ ып калдым, йөрү; ~ кан кырлар; **яраттырсаң**, нишләрмен; *сөю* – ~ еп карыйм; **сөел|ү** – ~ еп яшәргә язсын; **сөю-сөелү**; **сөю-сәгадәт** – ~ бүләк иткән язмышыма рәхмәтле; **сөйкемлелек** – ~ уратып алган; *гыйшык* – ~ тоту, ~ лык авыруы; *гашыйк* – ~ күңелен чит-ят аңламас, ~ булырлыгы бар; бер күрүдә ~ булдым; **гашыйклык** - ~ ка урын бирәмен; *дәрт* – беренче очрашуда сөю ~ е кабынды; **дәрт-дәрман** – ~ ы сүнмәде-сүрелмәде; *ошат|у* – беренче очрашуда ук бик ~ ты; *якын ит|ү* – бер күрүдә үк ~ те, яратты; ~ лык кылу.

*Мәхәббәт* сүзенең синонимик вариантлары *«Мәхәббәт»* антропонимик кырын репрезентацияләүдә бәяләп бетергесез әһәмияткә ия. *Ярату, сөю, гыйшык, гашыйк, дәрт «мәхәббәт»* сүзенең синонимик вариантлары, ләкин алар да, доминанта сүз кебек үк, күпмәгънәлелеккә ия. Мәсәлән, *ярату, сөю* сүзләре затка, субъектка гына түгел, объектка, предметка, күренешкә, процесска карата да кулланырга мөмкин.

Татар теленең антропонимик киңлегендә «мәхәббәт» мәгънәсен белдерә торган төрки-татар хатын-кыз исемнәре белән бергә гарәп-фарсы телләреннән кергән алынмалар да һәм алар белән катнаш компонентлы төрки-татар исемнәре дә шактый: *Байсөяр (төр.-т), Илдусә (төр.-т), Илсөяр (төр.-т), Илсөя (төр.-т); Маһрибикә (ф.-төр.-т), Мәхбүббикә (г.-төр.-т), Мәхүббикә/Хупбикә (г.-төр.-т)* һ.б.

«Мәхәббәт» мәгънәсен белдерә торган гарәп-фарсы чыгышлы хатын-кыз антропонимнары: *Вәдүдә (г.), Газалия (г.), Гатифә (г.), Гашикә (г.), Гашкыя (г.), Мәгазә (г.), Мәгъшукә (г.), Мәхбүбә (г.), Мәхәббәт (г.), Мәхүб (г.), Солтания (г.), Хөбби (г.) һ.б.; Дилбәр (ф.), Дилдарә (ф.), Диларә (ф.), Шәйдә (ф.), Миһри/Миһер (ф.) һ.б.; Хөббигөл (г-ф), Хөббизадә (г-ф), Мәхүббану (г-ф), Хөббиҗиһан (г-ф)* һ.б.

Тикшеренүләргә нәтиҗә ясасак, бүгенге көн татар антропонимиясендә *мәхәббәт* кырын тулыландыра торган берәмлекләр шактый күп. Әлеге берәмлекләр контекстта бер-берсен тулысынча алыштырып килә алмыйлар, чөнки һәрбер синонимик элемент *мәхәббәт* хисенең бер сыйфатын, билгеле бер дәрәҗәсен белдерергә генә сәләтле. Кулланылыш ешлыгы буенча карасак, мәхәббәт мәгънәсен белдерә торган

антропонимнар арасында гарәп теленнән алынган хатын-кыз исемнәре, исем компонентлары күпчелекне тәшкил итә. Әлеге күренешне мәхәббәт лексик берәмлегенең гарәп чыгышлы булуы белән генә аңлата алабыз.

**Әдәбият**

1. Галиуллина Г.Р. Татарские личные имена в контексте лингвокультурных традиций. – Казань: Изд-во Казанск. гос. ун-та, 2008. – 352 с.

2. Саттаров Г.Ф. Татар исемнәрн ни сөйли? – Казан: Раннур, 1998. – 487 б.